Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлегегенең Ивановка авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 21 ноябрь № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегегенең Ивановка авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 21 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлар, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 500 сум күләмендә акча керту һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

I. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Зиратка, Нагорная урамы буенча (3нче йорттан 10нчы йортка кадәр) һәм Заречная урамына кадәр (17нче номерлы йортка кадәр) юлларга вак таш җәю;
- Ивановка авылында (Үзәк, Октябрь, Яшьлек, Заречная, Нагорный, Энтузиастлар, Родничная, Мәктәп тыкрыгы) юлларны кардан чистарту .

II. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
-үлән чабу (Ивановка авылында гомуми файдаланудагы территорияләрдә үлән чабу хезмәтләре күрсәтү; ягулык-майлау материалларына чыгымнар).

III. Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру:
-Ивановка авылының Яшьлек урамы буенча балалар спорт комплексы сатып алу һәм урнаштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 365 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 185 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегегенең Ивановка авылында гражданнар җыены карар бирде:
1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге составына керүче Ивановка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган

яшәүчедән, 1 төркем инвалидлар, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

I. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Зиратка, Нагорная урамы буенча (3нче йорттан 10нчы йортка кадәр) һәм Заречная урамына кадәр (17нче номерлы йортка кадәр) юлларга вак таш җәю;

- Ивановка авылында (Үзәк, Октябрь, Яшьлек, Заречная, Нагорный, Энтузиастлар, Родничная, Мәктәп тыкрыгы) юлларны кардан чистарту .

II. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

-үлән чабу (Ивановка авылында гомуми файдаланудагы территорияләрдә үлән чабу хезмәтләре күрсәтү; ягулык-майлау материалларына чыгымнар).

III. Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру:

-Ивановка авылының Яшьлек урамы буенча балалар спорт комплексы сатып алу һәм урнаштыру карарын кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Ивановка авылы, Үзәк урам, 27 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.икасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ивановка авыл җирлеге башлыгы А.П. Бодряева